КӨТЕЛМӘГӘН КИМҮ

Сөенергәме, көенергәме: илдә пенсионерлар кими

> 2

АВЫЛ ИМАМЫ

«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары

> 3

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

Уяв уяу булып, гореф-гадәтләрне сакларга дигәнне аңлата

> 4

АЗДАН ГЫНА...

«Булгария» теплоходы баткан көнне, Иделдә чак кына фаҗига булмый калды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 98 (28871) | Сишәмбе | 12 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҮЗЕБЕЗНЕКЕ, ДИП КАЙТЫП КЕРӘБЕЗ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авылыбыз бетсә дә, аның капкасыннан, үзебезнеке, дип кайтып керәбез». Биектау районының Шыпшиек авылында яшәүчеләр әнә шулай ди. Уннан артык йорты булса да, кышын нибары икесенең морҗасыннан гына төтен чыга. Авыл җирлегендә исә, бу авылда беркем дә яшәми, дип беләләр. Тирә-юньдә дә кайберәүләрнең бу исемне беренче тапкыр ишетүләре. Шулай да бүген Шыпшиек кемгә кирәк соң?

Бик ышык урын

Кем өчендер беткән авыл булып саналса да, монда яшәүчеләр аны башкача кабул итә. Нәкъ балачактагы кебек шау-гөр килеп торган җылы бер урын итеп. Һәрхәлдә, Шыпшиек аларның күз алдында шулай саклана. Тарих битләренә күз салсаң, авыл атамасы «Шып-ышык» – бик ышык урын дигәнне аңлата. Чыннан да бу авыл бик тыныч җирдә, аланлыкта урнашкан.

XVIII–XIX гасырларда крестьяннар җир эшкәртү, мал-туар асрау, кирпеч сугу, туку, урман кисү белән шөгыльләнгән. XX гасыр башында авылда мәчет, мәктәп, тегермән, вак-төяк сату урыны булган, Халкы 545 кешегә җиткән. 1938 елдан соң халык саны кими башлый. Әйтик, 1970 елда –104,1989 елда – 9 кеше. Әлеге вакыйга авыл кешеләренең күрше авылларга һәм Казан тирәсенә күченүләренә бәйле. Авылда эш урыннары бетә, мәктәп ябыла. Авыл өч өлешкә бүленсә дә, бары тик бер урам – Коммунистическая урамы исәпләнә. Авылда клуб, кибет, мәктәп, кошчылык, ат, эре терлек фермалары булган. Менә шундый тулы тормыш белән яшәгән Шыпшиек шундый хәлгә калыр дип кем уйлаган? Авылның исеме җисеменә туры килгән түгелме?

Карап тормасаң, җимерелә

Соңгы могиканнар авылны саклап булмаячагын аңласа да, туган нигезне сакларга беркайчан да соң түгел, диләр. Шуның өчен шәһәрдән кайтканнар да инде. Лаеклы ялга чыккач... Хет шулай булсын. Биш йортка шәһәрдән «дачник»лар кайтып йөри. Аларның тамырлары бу авылныкы түгел. Шуңа күрә андыйларга авыл нибары ял итү, көч җыю урыны гына. Бетте, калмады дигәндә дә, адәм баласын авылга ниндидер җепләр бәйли. Моңа кадәр бөтен авылына бердәнбер кеше булган 96 яшьлек Разия әби бакыйлыкка күчкән инде. Сугыш ветеранының тол хатыны Шыпшиекка, иренә тугрылыгын саклаган, димәк. Хәер, андыйларның тормыш фәлсәфәсе без аңлый торганмыни? Күпләр бит авылда берүзең яшәүне җүләрлек яки кыргыйлык дип кенә бәяли. Хәзерге вакытта авылда кышны чыгучылар – Илсөя апа һәм Гөлсинә апа гаиләләре.

– Бу – минем туган җирем, үз авылым. Чит авылга алай дип барып буламыни? Шуның белән дә кадерле ул. Элек Алан Шыпшиек дип йөртсәләр, без Шыпшиек дибез, – ди авылга 4–5 ел элек күченеп кайткан 73 яшьлек Илсөя апа Бикбаева. – Әти дә, әни дә үлде... Өч абыем бар иде, алар мәрхүм инде. Мин – төпчеге. Карап тормасаң, нигез җимерелә бит ул. Абый гаиләсе белән җәй саен Мәскәүдән кунакка кайтып йөрде. Аларны җимерек сарай белән каршы алып булмый бит инде. Шуңа күрә йорт-җирне, каралты-кураны тәртиптә тотарга тырыштык. Ирем Җәмил Казанда туса да, әнисе – шушы авылдан. Ул авылга беренче булып кайтып китте. Мин атнага берничә тапкыр кайткалап йөрдем. Пенсиягә чыккач та алты ел эшләдем. Аннан инде мин дә авылга күчендем. Кышны үзебез генә чыккан чаклар да булды. Узган ел туганыбыз Гөлсинә белән ире Илгиз дә кышка яшәргә кайтты. Гөлсинә белән әтиләребез бертуган.

– Башта ферма, аннан мәктәп бетте. Мин шушы авылда башлангыч мәктәпне тәмамладым. Әти-әниләр кайда мәктәп бар, шунда китеп бетте. Кайсы – Казанга, кайсы – күрше авылга. Таркалу шуннан башланды, – дип сөйли Илсөя апа.

Илсөя апа кечкенә чагында авылда 100ләп йорт булган. «Ярты авылда – татарлар, яртысында керәшеннәр яши иде», – ди ул. Авыл өстендәге калкулыкта «Мәрьям Ана» урманы бар икән. Ул – изге урын, монда гөмбә, җиләк-җимеш җыярга да, агачларны кисәргә дә ярамый. Авылның алма бакчасы да булган (әле дә алмагачлары исән). Анда элек совхозның умарталыгы урнашкан. Алма бакчасы артында Явыз Иван заманында чукындырылган татарларның зираты булган. Бүген ул каберлекләр тигезләнеп беткән. Бары тик утыртылган агачларын гына күрергә мөмкин.

Кибеткә – чаңгыда, ләгән тагып...

Җәй көннәрендә авылга сөт, каймак, эремчек сатучылар килә. Тик кышын бер техника да керә алмый. Шуңа күрә кирәк-яракка 4 чакрым ераклыктагы Дөбьяз авылы кибетенә баралар. Гөлсинә һәм Илсөя апалар кышын чаңгыда, билләренә ләгән тагып, юлга кузгалалар. Чаңгыларын полосада калдыралар да Дөбьязга төшәләр. Яңгыр яуса, тауны менеп тә, төшеп тә булмый, диләр. Шуңа күрә алар өчен иң авыры – юл газабы. Элек авылда Разия әби ялгызы гына яшәгәндә, авыл җирлеге юлны атна саен тәртиптә тоткан. «Кыш көннәрендә юлны айга берничә тапкыр ачсалар да, рәхмәтле булыр идек. Автокибет җибәрсәләр дә, сөенер идек», – ди ике туган.

Мал-туар асраучы юк. Шулай да Илсөя апалар унлап тавык тота. Иртүк авылны уятырга әтәчләре дә бар. Җәйләре бакчада казынып, кышлары өйдә телевизор карап уза. Авылга газ кертелмәгән. Өйләрен утын ягып җылыталар. Кыш буена 1–2 машина утын кирәк икән. Бер йөген 18–28 мең сумга сатып алалар. Су проблемасы юк, өйләренә кертелгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Ятимнәргә 600 торак бирелә

Татарстан Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы 2013–2021 елларда ятимнәр өчен 3366 фатир сатып алган. Моңа барлыгы 3,7 миллиард сум (шул исәптән федераль үзәктән – 537 миллион сум) тотылган. Быел тагын 600 шундый торак сатып алу күздә тотыла. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин әйтүенчә, ятимнәргә торак биш елга төзелгән наем килешүе буенча бирелә. Шуннан соң ул хосусыйлаштырылырга мөмкин. Татарстанда бу эш 2018 елда башланып киткән.

Соңгы мәгълүматларга караганда, 1308 фатирны наемга алып тору срогы чыккан. Шуның 552се милеккә тапшырылган, 253е – социаль наем килешүе буенча бирелгән, 503е буенча, торак-коммуналь хезмәтләргә вакытында түләнмәү сәбәпле, «сынау», ягъни наем срогы тагын биш елга озайтылган.

Түләү тәртибе билгеле

Татарстанның «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүчеләргә бер тапкыр түләү тәртибе билгеләнгән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. Ихтыяриларга Министрлар Кабинетының резерв фонды хисабыннан түләнеләчәк. 260 мең сум күләмендә түләү алу өчен хәрби комиссариатка гариза, хәрби часть исемлегенә кертелү турында боерыктан өземтә күчермәсе, банктагы счет реквизитлары белән документ күчермәсе, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү кәгазен тапшырырга кирәк. Бер тапкыр түләү 5 эш көне эчендә күчерелә.

Исегезгә төшерәбез: «Алга» һәм «Тимер» батальоннары июнь аенда Луганск, Донецк халык республикаларында һәм Украинада махсус хәрби операциядә катнашу өчен булдырылды.

Экваторны узганнар

Республикада йортларны, башка объектларны капиталь төзекләндерү эшләре дәвам итә. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Алексей Фролов Президент үткәргән киңәшмәдә билгеләп үткәнчә, күпфатирлы йортларны төзекләндерү программасы 53 процентка үтәлгән инде. 59 йорт тулысынча әзер, 84ендә ремонт тәгәлләнеп килә. Шулай ук сәламәтлек саклау, мәдәният, экология, яшьләр сәясәте өлкәсендәге оешмалар биналарын яңарту эшләре тулы куәтенә алып барыла.

Атна ахырына җиләсләнә

Татарстан урманнарында янгын куркынычы турында кисәтү 15 июльгә кадәр озайтылган. Бу хакта Гидрометеоүзәк хәбәр итә. Моңа кадәр синоптиклар 5–11 июль чорында 4 нче класслы хәтәр турында кисәткән иде. Кисәтү тагын кимендә дүрт көнгә озайтыла.

Россия Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда, республикада пәнҗешәмбегә һава температурасы +30 градустан кимеячәк: термометрның терекөмеш баганасы +27...+28 градус тирәсен күрсәтәчәк. Ә җомга көнне көндезге температура инде +23...+24 градустан артмаячак. Шул ук вакытта атна буе яңгырлар көтелә.

Йомырка тәбәсе рекорд куячак

16 июльдә Питрәчтә инде менә алтынчы тапкыр «Скорлупино» Бөтенроссия фестивале узачак. Бәйрәмне оештыручы Наилә Таҗиева әйтүенчә, быел анда йомырка тәбәсе пешерү буенча яңа рекорд куярга җыеналар. Ашсу осталары, үзләре генә белгән серләрне кулланып, 8 мең йомыркадан галәмәт зур тәбә әзерләргә ниятләп тора. Рекорд 2,5х1,5 метр үлчәмендәге 4 таба һәм бик зур мангаллар ярдәмендә куелачак. Йомырка тәбәсен әзерләү өчен 100 кило чамасы күмер таләп ителә. Теләге булган барча кеше ризыкның тәмен татып карый алачак.

Таҗиева сүзләренә караганда, узган елгы фестиваль өчен әзерләнгән 200 литрлы самавыр быел да «эшләячәк». Бер мәйданчыкта чәй дегустациясе үткәреләчәк. Аны халык рецептлары буенча төрле үләннәрдән әзерләячәкләр. Чәй янына милли тәм-томнар тәкъдим ителәчәк. Сүз уңаеннан, 2019 елда фестивальдә 7777 йомыркадан рекорд куелган булган инде. Ә узган ел 450 килограммлы гигант торт бәйрәмнең төп бизәгенә әйләнгән.

Яңалык

Кредитка чират

Россиядә кулланучы кредиты очсызланган. Бер атна эчендә аларның процент ставкасы 3,93 процентка төшкән. Шул рәвешле хәзер әлеге төр кредитны уртача 18,6 процент белән алып була.

pixabay.com

«Финанс хезмәтләре» платформасы мәгълүматларына караганда, кулланучы кредиты ставкаларының май аеннан бирле әле беренче тапкыр гына шулай кисәк төшүе. 26 май көнне Үзәк банк төп ставканы 14 процентган 11 процентка калдыргач та ул 0,2–0,7 процентка гына төшкән иде. Бүген исә илнең 11 эре банкы (ВТБ, «Альфа-банк», «Газпромбанк», «Промсвязьбанк», «Росбанк», «Райффайзенбанк», «Мәскәүнең кредит банкы», «Хоум Кредит», «МТС Банк», «Уралсиб» һәм «Ак Барс») кисәк кенә кулланучы кредитларының процент ставкасын киметкән.

Финанс аналитигы Александр Гусев моны, иң беренче чиратта, кредитның тулы күләмен, ягъни заем алучы банкка кайтарырга тиеш булган сумманы көйләү хокукы кире кайтарылу нәтиҗәсе дип саный. Билгеле булганча, Үзәк банк 24 февральдән 30 июньгә кадәр бу мөмкинлекне вакытлыча туктатып торган иде. «Кредит индексы кимүгә төп ставканың төшүе, ил икътисадының тотрыклылануы да йогынты ясады», – ди белгеч.

Финанс аналитигы фикеренчә, төп ставкага бәйле рәвештә, якын киләчәктә илдә барлык төр кредитларның да ставкасы төшәчәк. Әмма бу эш тоткарлыклар белән барачак, дип саный ул. «Көзгә таба илдә эшсезләр саны бермә-бер артырга мөмкин. Бу исә илдә кредит алучылар яисә булган кредитын түли алмаучылар саны да артачак дигән сүз. Ул, үз чиратында, шулай ук кредит ставкаларының төшүенә этәрәчәк», – ди Александр Гусев. Рәсми саннарга ышансаң, быелның февраленнән илдә кулланучы кредитын вакытында түләп бара алмаучылар саны 4,6 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә «РИА новости» агентлыгы ипотека кредиты иң күп бирелгән төбәкләрне ачыклаган. Алар төзегән рейтингта беренче урынга Урал федераль округының төньягында урнашкан төбәкләр чыккан. Шул рәвешле белгечләр иң күп ипотека кредиты Төмән өлкәсендә бирелгән дип исәпләп чыгарган. Соңгы бер елда бирелгән 1 мең кешегә 37,3 заем туры килгән. Әлеге рейтингның икенче баскычында урнашкан Ханты-Манси автоном округында (Югра) шул ук бер мең кешегә – 35,3 кредит, Ямалда 34,3 кредит туры килә.

Иң күп ипотека кредиты бирелгән төбәкләрнең беренче бишлегендә Удмуртия белән Якутия дә урнашкан. Башкортстан, Новосибирск һәм Магадан өлкәләре, Татарстан, Пермь крае рейтингның беренче унлыгын йомгаклый. Кырым, Дагыстан һәм Ингушетия исә – ипотека кредиты иң аз бирелгән төбәкләр рәтендә.

Сүзгә-сүз

dumatv.ru

Максим ТОПИЛИН, Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт комитеты рәисе:

Күптән түгел «Алабуга» махсус икътисади зонасында булып кайттым. Минемчә, коллегалар, Финанс, Икътисади үсеш министрлыклары вәкилләре белән бирегә җыелып, импортны алыштыру өлкәсендә яңа проектлар буенча фикер алышу бик дөрес булыр иде. Миңа калса, безнең бурыч – профильле министрлыклар белән әлеге яңа проектларны тормышка ашыруга ярдәм итүне көчәйтү.

(«Парламентская газета»)

РОССИЯДӘ – КУНАКЧЫЛЛЫК

Кунакка йөрергә яратасызмы? Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан.



- **37%** айга бер-ике мәртәбә йөрүчеләр
- **25%** атна саен йөрүчеләр
- **24%** елга берничә мәртәбә йөрүчеләр
- **14%** елга бер яки бөтенләй йөрмәүчеләр

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЛИДЕРЛАРНЫ ТҮНТӘРГӘНДӘ

Үткән атнада вакыйгалар социаль системалар нык чайкалганда гына күзәтелә торган кайнар эздән акты. Бәяләрнең ашкын күтәрелүе, халыкларның бөлгенлек чигенә килеп терәлүе дөньяның төрле почмакларында рәсми хакимиятләрнең абруен нык какшатты, көн тәртибенә лидерларны түнтәрү, мәҗбүри отставкаларга җибәрү килеп басты, революцион вазгыять борынлый һәм аваз бирә башлады. Беренче булып дефолт игълан иткән Шри-Ланка халкы бәйдән ычкынды. Илдә болай да анархиягә тиң хәл формалашкан иде инде. Ягулык кыйммәт бәягә дә юк, бәяләр векторы текә рәвештә күккә күтәрелә. Халык, үчегеп, депутатларны, зур дәүләт чиновникларын эзәрлекли һәм хәтта үтерә. Атна ахырында вакыйгалар үзләренең югары ноктасына иреште. Ил башкаласы Коломбада Президент Готабаи Раджапакс резиденциясенә гыйсъянчылар бәреп керде. Хәрбиләр Президентны качырып өлгерделәр, әмма хакимлек кулдан ычкынды. Ул да түгел, Премьер-министр йортын ут ялмавы турында хәбәрләр ишетелде. Күп кенә депутатларның йортлары да шундый язмышка дучар булды. Кытай кредитларына баткан ил бурычлар йөгеннән егылды. Россиягә акчалата ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән ил лидеры, ярдәм килгәнче, дилбегәне тотып тора алмады.

Лондонда исә хакимият алыштыру башка сценарий буенча оештырылды. Борис Джонсон секс-җәнҗал тырмасына китереп басты. Пинчер – Консерватив партиянең парламент фракциясендәге координаторы – элиталы клубта исерек килеш ике иргә бәйләнгән. Аның ирләргә карата мәхәббәте нигезендәге андый кыланмышлары элек тә булган инде. Джонсонны шундый җәнҗаллар белән бәйле кешене югары постка билгеләүдә гаепләп, башта сәламәтлек саклау министры Сәҗид Җәвид (чыгышы белән этник мөселманнардан) белән финанс министры Риши Сунак отставка игълан иттеләр. Джонсон кабинетында эш ташлаучы түрәләр саны илледән ашып киткәч, кәнәфигә нык ябышып калырга теләгән Премьер-министр да королевага үзенең отставкасы турында белдерергә мәҗбүр булды. Бу атнада Англиядә Джонсон урындыгы өчен көрәш башлана. Җәнҗаллы Премьер көзгә кадәр эшен дәвам иттерәчәк әле. Аның китүе Кремльдә шатлык тудырды, чөнки пычранган лидер Украина мәйданында Россияне тар-мар итү тарафдары иде.

Джонсонга бәйле җәнҗал тынып та өлгермәде, Германиядә канцлер Шольцка кагылышлы күңелсез факт турында хәбәр таратыла башлады. Немец газетасы «Tagesspiegel» һәм берничә мәгълүмат агентлыгы канцлер катнашындагы кичәдә ким дигәндә 8 хатын-кызга «көчләү наркотигы» бирүләре турында җәнҗал тараттылар. Андый наркотик кулланган кешеләр үзләре белән ни булуын хәтерләми икән. Әлегә җәнҗал зур яңгыраш алып өлгермәде, әмма Джонсон стилендәге түнтәрелешнең теләсә кайсы сәясәтче белән була алуын искәртте. Инфляция күтәрелгән саен, Европа лидерларының рейтингы түбәнгә тәгәри һәм яңа җәнҗаллар сериясе көтелми дип әйтеп булмый. Әхлаксыз Европада андый отставкаларны оештыру бик җиңел.

Җомга көнне Японидә элекке Премьер-министр Синдзо Абэны кулдан ясалган утлы коралдан атып үтерделәр. Абэ гамәлдәге лидер булмаса да, аның Кеннеди үлеменә охшаган үлеме лидерлардан котылуның мондый ысулы да барлыгын искәртә. Бу юллар язылганда гына Аргентинадан хөкүмәткә каршы зур урам хәрәкәте башлануы турында видеофактлар килде. Ул илнең икътисад министры Мартин Гусман 7 июльдә отставкага киткән иде инде.

Россиядә

ПЛАННЫ УЗЫП КИМҮ

Россиядә дә вазгыять катлаулы, билгеле. «Русская сталь» ассоциациясе вице-президенты Андрей Леонов 200 мең кеше эшләгән металлургия заводларының домна мичләрен һәм прокат линияләрен туктатырга мәҗбүр булулары хакында хәбәр итә. Башка тармакларда да шуңа охшаган хәл күзәтелә. Экспортка чимал сату кими, шул җитештерүчеләргә каты итеп суга. Әмма бездә бер сөенечле хәл бар: 1991 елдан соң беренче тапкыр илдә дефляция – бәяләрнең төшүе күзәтелде. Росстат аның июньдәге күләмен 0,35 процент дип бәяләде. Дөрес, бу песи ялаганнан да кимрәк инде кимрәген. Акча янчыгы сизәрлек тә түгел. Ләкин барыбер хәбәр шатлыклы. Тагын бер нәрсә бар: бу сезонлы бәя төшү генә түгел. Сезонлы дефляция көз көне яшелчәләр өлгергәч кенә күзәтелә иде. Аннан соң яшелчәләргә генә түгел, сәнәгать товарларына, бигрәк тә төзелеш материалларына бәяләр сизелерлек төшә. Бик нык югары күтәрелгәннән соң төшә инде алар, шулай да күңелгә рәхәтлек бирә. Дефляция озын гомерле булыр дип әйтеп булмый, чөнки хөкүмәтнең финанс блогы бәяләр төшүгә борчыла. Сумны йомшарту башланды инде. Доллар күтәрелә, аңа ияреп бәяләр дә югары китәргә ихтимал. Тик халыкның сатып алу мөмкинлеге чикләнгән. Бәяләрне арзанлы кредитлар белән кабартырга тырышалар.

Сөенергәме, көенергәме икәнен аңлап булмый торган тагын бер күрсәткеч мәйданга чыкты: илдә пенсионерлар саны планны узып кими. Әйе, әйе, шундый план бар. Пенсия яшен күтәргәндә, табигый рәвештә лаеклы ялдагы өлкәннәр саны кимү көтелә иде. Шул хисапка исән килеш пенсиягә чыгучыларның картлык акчасын күтәрү дә, Пенсия фондына бюджеттан акча түләүне (трансфертны) туктату да ниятләнгән иде. Соңгысы, бюджет трансфертыннан башка яшәүче Пенсия фонды, 2030–2031 елларда гына барлыкка килергә тиеш иде. Әмма вакыйгалар ашыга, планны узалар. Россиянең Пенсия фонды планы буенча 2021 елда пенсия алучылар саны 300 меңгә кимергә тиеш булса, чынлыкта кимү 1 миллионга җиткән. 2022 елда да план күп тапкыр арттырылып үтәлер дип көтәләр. Пенсия фонды фаразы буенча быел пенсия алучылар саны 384,6 меңгә кимер дип уйланыла. Әмма 1 апрельгә үк инде кимү темпларының көтелгәннән югарырак булуы күзәтелә.

Пенсия фонды үзе дә Социаль иминиятләштерү фонды белән кушылып юкка чыгарга тора бит әле. Федерация Советы фондларның берләшүен үткән атнада хуплады. Кушылу икътисади яктан отышлы булыр дип уйланылса да, отышның параметрлары әлегә мәгълүм түгел. Икътисади хәл начараю сәбәпле, Пенсия фондына түләнә торган взносларның кимүе ихтимал.

Соңгы сәгатьләрдә генә Дәүләт Думасының 15 июльдә чираттан тыш утырышка җыелачагы мәгълүм булды. Кичектерми хәл итәлергә тиешле мәсьәләләр күп җыелды, диләр. Хөкүмәт яңа инициативалар белән дә чыгарга җыена икән. Вазгыятьнең кискен үзәреп торуы шартларында бу гаҗәп түгел.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

САКЛАНГАННЫ САКЛАР

Коронавируска каршы күмәк иммунитетны ныгыту, җәйге ял вакытында балаларның иминлеген тәэмин итү, КПРФ Үзәк комиссиясе рәисе Геннадий Зюганов белән очрашу... Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның эш көндәлеге бу көннәрдә әнә шулардан гыйбарәт иде.

tatarstan.ru

Мирасның кадере бар

Узган елларда Татарстанга эш сәфәре белән КПРФ Үзәк комиссиясе рәисе Геннадий Зюганов килде. Ике көн дәвамында ул Казан федераль университетында, В.И. Ленин музей-йортында, Свияжск утрау-шәһәрчегендә булды, Әлки районында узган Уяв чуаш мәдәнияте бәйрәмендә дә катнашты. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда алар республиканың социаль-икътисади үсеше, КПРФның Татарстан бүлеге белән хезмәттәшлек, совет мирасын саклау кебек актуаль темалар уңаеннан фикер алыштылар.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда тарихи-мәдәни мираска бик сак карауларын искәртте. Татарстан Президенты бу урында төрле елларда Казанда төзекләндерелгән В.И. Ленин музей-йортын, мәдәният-ял комплексын, В.И. Ленин экспозициясе һәм Ленино-Кокушкино экспозицияләрен, Казан үзәгендәге реставрацияләнгән В.И. Ленин һәйкәлен дә телгә алды. Геннадий Зюганов, үз чиратында, Рөстәм Миңнехановка тарихны саклау мәсьәләләренә игътибарлы караулары өчен рәхмәт белдерде.

Тынычланырга иртәрәк

Covid-19га каршы күмәк иммунитетны ныгыту эшен дәвам иттерергә кирәк. Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган республика киңәшмәсендә шулай дип белдерде. Татарстан Президенты сүзләренә караганда, соңгы атнада республикада коронавирус белән авыручылар саны 9 процентка кимегән. Эпидемиологик вазгыять тотрыклылану сәбәпле, ковидка бәйле рәвештә кертелгән барлык чикләүләрне туктатып тору турында карар кабул ителгән.

Әмма белгечләр бертавыштан тынычланырга иртәрәк дип кисәтә. Ник дигәндә, бик тиздән авырулар кабат ешая торган көзгә аяк басачакбыз. Моңа утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та игътибар итте. «Пандемиянең кискенләшүенә юл куймас өчен, вакцинацияләү буенча эшне көчәйтергә кирәк. Төркиядә, Италиядә, туристлар күпләп ял иткән башка урыннарда ниләр булганын күреп торабыз. Анда вазгыять тотрыклылану ягында түгел. Шуңа күрә халыкны вакцинацияләү һәм иммунитет мәсьәләсе элек ничек актуаль булса, бүген дә шулай булып кала бирә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Иминлек – беренче урында

Рөстәм Миңнеханов, балалар савыктыру лагерьларындагы санитар-эпидемиологик вазгыять тә даими рәвештә контрольдә булырга тиеш, дип кисәтте. Республика киңәшмәсендә балаларның иминлеген тәэмин итүне җитди контрольгә алырга кушты ул.

Балалар лагерьларында беренче ял сменасы тәмамланды. Бу эшкә шәһәр яны, мәктәп яны, палаткалы лагерьлардан торган 1195 ял оешмасы җәлеп ителгән. Беренче сменада 86,5 меңнән артык бала ял иткән. Республика лагерьларында икенче смена башлана. Анда 23,5 меңнән артык бала барачак. Кара диңгез буенда исә хәзер Татарстаннан 1386 бала ял итә.

Рөстәм Миңнеханов июль башында Кырымда «Сәләт – Акбарс» исемле яңа лагерьның беренче сменасы эшли башлавын да искәртте. Бүген анда портфолио бәйгесе аша сайлап алынган 14–17 яшьлек Татарстан һәм Кырым Республикасы балалары ял итә. Җәй буена исә биредә барлыгы 600дән артык бала ял итәчәк. «Балаларның иминлеген тәэмин итү, санитар нормаларны катгый үтәү – җәйге ялны оештыруда мөһим бурыч», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул Роспотребнадзор җитәкчелегенә, Яшьләр эшләре министрлыгына, район һәм шәһәр башлыкларына балаларның ялын оештыруга карата таләпләрне тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә кушты.

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНАЛАР

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Абхазия Халык Җыены (парламенты) Рәисе Лаша Ашуба белән очрашты. Казанга ул кайбер юнәлешләр, шул исәптән законнар чыгару юнәлеше буенча Татарстанның эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен килгән.

Фәрит Мөхәммәтшин Россия – Абхазия хезмәттәшлеге кысасында парламентара элемтәләрне үстерүгә ышаныч белдерде. Ул шулай ук Дәүләт Советының профильле комитетлар, алар каршында оештырылган экспертлар советлары, фракцияләр һәм депутатларның эшчәнлеге турында сөйләде.

Абхазия парламенты спикеры социаль әһәмиятле законнар әзерләгәндә һәм кабул иткәндә экспертлар белән хезмәттәшлек итү буенча Дәүләт Советының эш тәҗрибәсе белән кызыксынды. Хәзерге вакытта Татарстан парламентының сигез комитеты каршында экспертлар советлары эшли. Аларга дәүләт һәм муниципаль органнар, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни учреждениеләр вәкилләре керә. Фәрит Мөхәммәтшин искәртеп үткәнчә, нәкъ менә экспертларга законнарны куллануны анализлау йөкләнә. Моннан тыш экспертлар советлары әгъзалары, республика законнарындагы яңалыклар турында сөйләп һәм халыкны законнар иҗат итүгә тартып, зур аңлату эшләре башкара.

Абхазия – Татарстанның мөһим партнерларыннан берсе. Татарстан белән Абхазия арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү инде 1994 елда ук төзелгән. Узган елда ике республика арасында тышкы сәүдә әйләнеше 17 миллион доллардан артыграк тәшкил иткән. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, төбәкара элемтәләрне көчәйтеп җибәрү өчен мөмкинлекләр бар. Сәүдә-икътисади хезмәттәшлеккә генә түгел, бәлки әле парламентара һәм гуманитар хезмәттәшлеккә дә кагыла бу. Әлеге тәкъдимне Абхазия Халык Җыены Рәисе тулысынча хуплады.

Теләкләр кабул булсын

Төрекмәнстанның Милли Генгеш Халык Маслахаты (парламенты) Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәдов Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин адресына Корбан бәйрәме уңаеннан котлау телеграммасы юллаган.

«Сезгә ихлас күңелдән изге бәйрәм уңаеннан котлауларымны ирештерәм, – дип билгеләп үтә Гурбангулы Бердымөхәммәдов телеграммада, – сезнең барлык изге теләкләрегез һәм эшләрегез Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул ителсен. Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер һәм бәхет, ә Татарстанның тугандаш халкына тынычлык, иминлек һәм республиканың чәчәк атуын телим».

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз өченче утырышы 14 июль көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.
Дәүләт Советы депутатларын теркәү Дәүләт Советы бинасында 14 июльдә 8.00 сәгатьтә башлана.
Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Үзебезнеке, дип кайтып керәбез

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Үкенсәк, кайтмас идек

75 яшьлек Илгиз абый Әскәров әнә шулай ди. Бу йортта хатыны Гөлсинә апа белән яшиләр. Икесе дә – шушы авылдан. Без килгәндә, Гөлсинә апаның шәһәргә киткән чагы иде.

– Монда иркенләп яшибез. Ковид вакытында урамга да битлексез чыгып булмады бит. Авылда күкрәк тутырып һава сулыйбыз. Кошлар сайравын тыңлыйбыз. Шәһәр белән чагыштырырлык түгел. 2009 елдан җәй көннәрендә авылга кайтып йөри башлаган идек. Быел беренче мәртәбә кышны чыктык. Юлы, кибете булса, түзәрлек. Хатын продукцияне бер айга җитәрлек итеп сатып алып куя. Балалар кайтып, хәлне белешеп тора. Яңалыкларны телевизор, интернеттан карап беләбез. Бәрәңге утыртабыз, яшелчә, җиләк-җимеш үстерәбез. Эшсез аптырап ятмыйбыз, – ди Илгиз абый Әскәров.

Илгиз абыйның авылның бетүенә йөрәге әрни. Тик бездән генә тормый, ди. «Кечкенә генә авыл булса да, элек бөтен нәрсәсе бар иде. Колхоз, мәктәп бетте. Без шуңа шәһәргә качтык та инде. Эше, мөмкинлекләре булса, кеше авылдан китмәс иде», – ди ул.

Шыпшиек халкы авылга юлны бөтенләй онытып бетерми әле. Зиратын тәртиптә тота. Соңгы елларда бигрәк тә игътибар арткан. «Әгәр юлы булса, авылга башкалар да күченеп кайтыр иде. Кайберәүләр җир алса да, юл газабыннан куркып, йорт салырга ашыкмыйлар. Кыш көне машиналарын юл читендә калдырып булса да, кайталар бит. Хатыннары шунда көтеп утыра. Табигате матур, тыныч. Рәхәтләнеп яшәргә була», – ди авылда яшәүчеләр.

Шыпшиеклыларның гозерләрен Дөбьяз авыл җирлеге башлыгы Рамил Галиуллинга җиткердек. Әлеге вазыйфада икенче ел гына эшләүче башлык әлеге авылда кешеләр яшәвен бездән ишетте.

– Безнең җирлектә ике беткән авыл бар. Таршна авылында бер йорт та юк. Тик берәү анда мал-туар асрый. Шыпшиекта исә пропискада торучы бер кеше дә юк. Кышын анда юл чистартылмый. Ник алар, шунда торгач, пропискага керми икән? Халкы булган авылларны юлсыз калдырмыйбыз. Монда кешеләр кайтып утырган, ә без бу хакта белмибез дә. Авылга барып, хәлләрен белешермен, проблемаларын ачыкларммын, – дип вәгъдә итте Рамил Галиуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

СУ КАДЕРЕН... СУСЫЗ БЕЛӘ

Авыл сулышы

Күптән түгел авылыбыз белән су кадерен искә төшерергә форсат чыкты. Көн саен яңгыр явып торган көннәрдә дә сусыз калып була икән бит! Ярты сәгатьләп элек кенә шаулатып яңгыр явып үтүгә, малларга эчертергә су алыйм дисәм, краннан су бик акрын килә. Ярты чиләк тутыруга, бетте дә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шул арада «Ватсап»тагы авыл төркеменә: «Водокачка эшләмиме әллә ул?», «Нәрсә булды?», «Бүген булачакмы?» ише сораулар яза башладылар. Әлеге насосларны карап эшләтүче Гөлүзә җавабын озак көттермәде: «Насос эшләми, хәзер электриклар чыга». Берәр сәгать тыныч кына көттек. Аннан инде суның бүген булмаячагы билгеле булды. Озак та тормады, шушы ук төркемгә авыл җирлеге башлыгы Рәсим Латыйпов: «Кемнәрнең малларына, юынырга су кирәк, хәзер пожарный машина белән алып чыгабыз», – дип язды (шаккатмалы хәл, шулай бит? Зур цистерна белән алып та чыктылар – рәхмәт дими, ни дисең бик тиз оештырган кешеләргә). Кемнәрдер, без су туплап калдык, дисә, сусыз калучылар да булган. Ярый әле, 200 литрлы бер мичкәнең суын бетереп, чистартып тутырган идек, малларга тотарга әнә шул су ярады. Крандагы суга ышанып, авыз шактый «пешкәләгәч», без үзебез кырыгар литрлы ике бидонда запас суны бетермибез. Эчәргә тотарга шул ярады. Иртән күрше авыл чишмәсеннән алып кердек. Кичтән үк зур савытлар белән суга чыгучылар да булды. Кыскасы, бер тәүлек тирәсе суны элекке авыл гадәте буенча тоттык. Әмма инде хуҗалыктагы бөтен краннардан су туктаусыз агып торуга шулкадәр ияләшеп җиткәнбез: кранның «колагы»н борып җәфаландык. Кул юарга кирәк булса да, кранны күтәрәбез, эчәсе булса да... Без генәме әле! Шәһәрдән кайткан мәчебез краннан аккан су эчәргә ярата. Аны инде тамчылатып, бик аз гына ага торган итеп көйләп, эчертәбез. Юк, савытка салган суны эчми генә бит, су беткән көнне дә, әле бер, әле икенче кранга карап, кычкырып тик утыра. «Сиңа түгел, үзебезгә дә юк әле», – дим.

... Табак-савыт юу үзе бер проблема булган икән... Аерым савытка су алып юулар бөтенләй онытылган! Ышанам, озакка гына китмәсә ярар иде, керләрне ничек юарбыз, дип кайгыручылар да шактый булгандыр, үзем дә, ярый әле көндез генә юган идем, дип сөендем. Ул көннәрдә бакчадагы яшелчәләргә дә су сибәсе юк иде, аларга сибәргә күпләрнең су запасы бөтенләй калмаган булып чыкты (яңгырлы чор булгач, запаслану кирәк тә түгел кебек)... Дөрес, авылда су икенче көнне үк булды. Булуга, бөтен мичкәләрне тутырып куйдык. Сабак алганнар икән дип уйлый күрмәгез, бу уңайсызлык хәзер онытыла ул, икенче су беткән очракта инде тагын шушы хәл кабатланачак (безнең авыл мисалында гына да беренчесе түгел). Ярый әле, авылда су әллә нигә бер бетә. Бәлки сабак алмау, әзерлек чаралары күрмәүнең тагын бер сәбәбе шушыдыр.

Кыскасы, заман уңайлыкларына карап, шәп җайлашканбыз икән инде. Бер көн ут, газ булмый дисәләр (гадәттә әллә нигә бер техник карауга-ремонтка туктаталар), алдан чарасын күрә башлыйбыз. Инде берәр көнгә димим, берничә сәгатькә телефон элемтәсе юкка чыкса... – моңа кадәр телефонсыз ничек яшәдек икән, диешәбез. Уңайлыкларны да, аларга ияләшүне дә начар димим, тормыш алга бара, димәк, авылныкылар да аннан калышмый. Әмма шушы уңайлыкларга карап, ияреп, еш кына исраф итүне дә уйламыйбыз шул. Әлеге дә баягы суны гына алыйк. Краннан су акмый башлагач, их, кадерен белмәгәнбез икән, дигән уй килә дә алга таба кадерен бик белербез кебек тоела. Тик краннан су ага башлауга, тукран тәүбәсе кебек, бу ниятебез дә онытыла. Агамы, ага... Замана ул... мана, дигән шагыйрь мең хаклы, димәк.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

БӘХЕТ ЮЛЫ

Дус кызым Чулпан белән балалар арбасы этеп, юл кырыеннан баруыбыз. Каршыбызга маршрут автобусыннан төшкән өлкән яшьтәге апа белән абый очрады.

– Сез Райнур хәзрәтнең әти-әнисеме әллә? – дип сорадым, абый кешедә таныш төсмерләрне күреп.

– Әйе, – диделәр туктап һәм, елмаеп, юлларын дәвам иттерделәр. Шул вакытта аларга кабат эндәшеп: «Райнур хәзрәтнең үтемле, шул ук вакытта кызыклы вәгазьләрен тыңлау, аның белән аралашу нәтиҗәсендә, тормыш иптәшем Айнур – шөкер, бүген биш вакыт намаз иясе, Кукмара мәдрәсәсендә белем ала, гомумән, тормышыбыз тамырдан үзгәрде. Шундый ул тәрбияләп үстергәнегез өчен бик зур рәхмәт сезгә», – дип әйтәсем килде. Кыенсындым. Әлеге язмам аша Кукмараның Таҗи Гыйззәт урамында яшәүче Халисә һәм Әлфәт Газизовларга әйтелмичә калган ихлас рәхмәтләрем барып ирешсен иде.

33 яшь кенә әле үзенә. Шулай булса да, күпләрне җитәкләп диярлек ислам диненә алып кергән, олысы һәм кечесе белән дә һәрчак уртак тел таба алган һәм, әлбәттә, бик күпләрнең хөрмәтен яулаган хәзрәтебез ул безнең. Үзенә тарту көче бар, йөзеннән нур бөркелә, аның белән исәнләшкәндә хәтта кочаклап, аркасыннан сөеп аласы, сөйләшәсе килә, вәгазьләрне халыкчан, аңлаешлы итеп, ялыктырмыйча сөйли, диләр Райнур хәзрәт турында. Ә ике юл чатында калган яшүсмерләргә адашып китмәс өчен дини гыйлем белән бергә дөньяви якны да берләштереп биргән дәресләре аерым хуплауга лаек.

«Абзый»ның беренче адымы

1993 ел. Кукмарада төзелгән мәчетнең манара кую һәм ачылыш тантаналарына, әнисенә ияреп, 4 яшьлек Райнур да бара. Орчык кадәр генә булса да, мәчеттә укулар оештырыла, чакырып калабыз, дигән игъланны сеңдерә ул. Әмма икенче көнне шунысы билгеле була: аның яшендәге балалар белән шөгыльләнерлек мөгаллим булмый, күрәсең, Райнурны, әзрәк үскәч, укырга килерсең, дип озатып калалар. Өенә кайтып, әнисенең ашарга дәшүенә дә игътибар бирмичә, залдагы чуен торбаны кочаклап елап утырганын әле дә онытмый ул. Эшнең нидә икәнен аңлап алган әтисе, аны җитәкләп, янә мәчеткә китә. «Утырып кына булса да торсын инде», – ди ул мәчет картларына. Якты күңелле бабайларның кем булганын хәтерләмәсә дә, шуннан соң үзен һәрвакыт үз итеп, якын итеп: «Абзый килде», – дип каршы алганнарын бүген дә елмаеп искә ала Райнур Газизов.

Шуннан бирле мәчет аның даими «эш» урынына әверелә. Абыйсына ияреп йөреп, аннан кабатлап, намаз уку тәртибен өйрәнә. Ә беркөнне әле биш яше дә тулмаган Райнурга абыйсыз гына мәчеткә барырга туры килә. Һәм ул беренче тапкыр үзлегеннән намаз укый. Булдыра алганын аңлап алган сабый, өенә очынып кайтып, суыткыч янына басып, әнисенә яңадан кабатлап күрсәтә. (Бу вакытта әле әтиәнисе дә намазда булмый. – **Авт.**)

2001 ел. 12 яшьлек Райнур мәдрәсәне тәмамлый. Әмма ул әле дә мәчеттәге олылар өчен яраткан «абзый» булып кала бирә. Чөнки мәчет сукмагына тузан да кундырмыйча намаз укырга, аралашырга шунда йөри. Янилдәге көллиятне тәмамлагач та, берничә юнәлештә: металл савыт-сабалар заводында, машина юу цехында эшләп ала. Кулы – хезмәттә, ә күңеле исламда була аның.

2009 ел. Бер хәзрәтнең: «Аллаһның диненен өйрәнергә тәкъдим яки мөмкинлек булганнан соң да барыйммы икән, юкмы дип икеләнеп торсаң, шул вакыт өчен дә җавап бирәсең була», – дип әйткән сүзе инде берничә ел егетнең күңелендә «әйләнә». Казандагы Россия ислам университетына укырга керсә, атна саен Кукмарадагы дуслар-танышлары белән күрешергә туры киләчәк; үз гомерендә бер тапкыр да хәрамны кулланмаса да, тирә-юнь барыбер өстерәргә мөмкин бит, дигән уй белән читкәрәк барып уку юлын сайлый ул. Ни хикмәт, Мәскәү ислам университетына шалтыратса – документлар кабул итәргә берничә көн калганы билгеле була. Әнисе ике ит бәлеше пешереп, әтисе бер капчык бәрәңге алып, гаилә поезд белән юлга чыга. Бәрәңге соңыннан ай буе ашарга җитсә, ә бәлешләрнең таба төбенә булачак студентлар бергәләп тиз төшәләр.

Кәсепчелек – яшәү чыганагы

2014 ел. Казандагы Россия ислам университетында читтән торып укучы, моңа кадәр Чаллы мәдрәсәсендә белем биргән Райнур (аягы сыну сәбәпле, Мәскәүдәге уку өзелә) гаиләсе: тормыш юлдашы Рузилә, уллары Мөхәммәтәмин белән туган нигезенә кайтып урнаша. Тормышны ничек тә алып барырга кирәк булганлыктан, кәсепчелек эшенә беренче адым ясала: җиңел машиналарын сатып, корбанга 74 баш сарык алына. Әмма 25 яшьлек Райнурга зур эш – хаҗ сәфәренә баручы төркемне җитәкләү бурычы куела. Ул әйләнеп кайтканчы, Рузилә өйдәгеләр ярдәме белән бөтен сарыкларны урнаштырып куйган була инде.

2022 ел. Шушы үткән еллар эчендә никадәр дини гамәл кылынган да никадәр эш башкарылган! Зур Кукмара авылындагы яңа йортларына күченгәнче, бирегә абзар салып, йомырка салучы бер мең тавык асрау, машинага бензин салырлык акча булмаган чакларда да көн саен авылларга йөреп, дини белем бирү, корбанга 320шәр сарык тәрбияләү, теплица төзеп, меңнән артык төп бакча җиләген формалаштырып сату дисеңме…

Гаилә архивыннан

Көн саен салынган йомырканы урнаштыру максатыннан, безе торты җитештерә башлаулары да – үзе бер кызыклы тарих. Бүген Газизовларның ике кондитер цехында 16 кеше эшли, көненә 1500 данә «Рурайам» безе торты, 200 килограммнан артык «Вена вафлие» җитештерелә. Алар Татарстанның барлык төбәкләренә, Башкортстан, Ульяновск, Удмуртия якларына таратыла. Бу көннәрдә Мәскәү белән сөйләшүләр алып барыла. Әле бит Кукмараның Туеш мәчетендә икенче имам булып эшләргә дә, коуч оста буларак дәресләр алып барырга да, Мөхәммәтәминне, кызлары Сөембикә һәм Җиһанны тәрбияләүне дә аксатмаска кирәк. Кукмарада яңа мәчет төзүнең оештыру эшләре дә аңа йөкләнелгән.

Күз тимәсен, өлгерә, булдыра, тырыша безнең Райнурыбыз. «Ислам ул – барлык кагыйдәләрне үзенә туплаган, безне бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә илтә торган юл», – ди ул. Әмин, шулай була күрсен.

Лилия НУРГАЛИЕВА.
Кукмара

922
2022
Идел буе Болгар дәүләтендә
Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Көтеп алынган кунак

Әлки районының төньягында – тау башында – бик матур бер авыл бар. Минем туган җирем – Карга авылы ул. Каргада да мәчет бар. Ул инде элек-электән авылыбызның изге йорты булып саналган һәм халыкка хезмәт итә. 2008 елда бирегә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсен тәмамлап, Питрәч районы Шәле авылы егете, 22 яшьлек Ирек Гомәр улы Сәлахиев имам булып эшкә килде. Авыл халкы олы яшьтәге имамнарны гына белә. Ә бу – япь-яшь. Бераз шикләнеп караучылар да булды. Яшь имам исә чын күңелдән яраткан эшенә кереште.

Ул туктаусыз хәрәкәттә, кайда ярдәм кирәк, шунда бара. Вәгазьли дә, үгетли дә, йолаларны да башкара, олысына-кечесенә дини белем бирә. Искиткеч сәләтле егет, хәзер инде ничек кенә мактамыйлар үзен. Менә инде 14 ел буена ул безнең авылның гына түгел, Әлки районының төп кешесенә әйләнде. Чөнки 2016 елның декабреннән аны мөхтәсиб итеп тә билгеләделәр.

Районыбызда 30 мәчет бар. Күпчелек имамнар олы яшьтә. Хәзрәт яшь имамнар әзерләү эше белән дә шөгыльләнә. Төрле проблемаларны чишәргә булыша. Мәчетләрне документлаштыру эшләрендә дә үзе башлап йөри.

Бер карыйсың, ул районда җыелышларда чыгыш ясый, икенче карасаң, халыкка үгет-нәсыйхәт бирә, хәйрия эшләре белән дә шөгыльләнә. Аз керемле гаиләләргә, ятим балаларга, ялгызларга, Юхмачыдагы картлар приютындагыларга даими ярдәм оештыра. Авылыбызда акылга җиңел өч егет бар. Алар да имамыбыз ярдәме белән намазга өйрәнделәр, мәчеттә җыештыру эшләрен дә башкаралар. Әлхәмдүлилләһи, тәртипле генә мәчеткә йөриләр.

Ул эшләгән елларда мәчетебез ике тапкыр капиталь ремонтланды. Идәннәре җылытылды, зәвыклы җиһазландырылды. Хәзрәтебезнең тырышлыгын санап бетергесез. Мәңгелек урыныбыз зиратны да тәртиптә тота. Ул эшләгәнче, куе агачлык, куаклар, чүп-чар баскан иде. Ел саен язга чыгуга, авыл халкын оештырып, зиратны чистарталар. Капкалары, тирәсе тимер рәшәткәләр белән тотып алынган. Авылыбызның иң хөрмәтле кешесе, олысы-кечесенең якын дусты, шәкертләренең яраткан остазы ул Ирек хәзрәт. Районда гына түгел, республикада да үрнәк булырлык безнең имамыбыз.

Ул җәмәгате Гүзәл белән тәртипле өч ул үстерә. Уллары да әтиләреннән дин белеме алып, менә инде берничә ел тәравих намазына йөриләр. Аның гаиләсе – авылда үрнәк гаиләләрнең берсе. Кош-корт үстерәләр, умарта тоталар. Ул җәй көне балалар, әби-бабайлар белән мавыктыргыч уеннар да оештыра. Шуңа күрә безнең авылда тәртипсезлек кылучы балалар юк.

Безнең имам – авылның һәрбер йортында көтеп алынган кунак. Ул булмаган, ул кермәгән йорт юк. Аны тирә-як авылларда да көтеп алалар. Яшь имамыбыз бар эшкә дә өлгерә, чөнки ул чын күңелдән яраткан эшендә эшли. Әлки районы Карга авылына килсәгез, күрәсез инде безнең имамыбызны. Хәзрәтнең теләге гади: бөтен халык иманга килеп, дин юлына бассын иде, хаклык белән идарә итәргә насыйп итсен иде, акыллы киңәшләр бирерлек зиһен бирсен иде, дип сорый ул аһәңле матур аңлаешлы итеп Раббыбыздан. Аллаһы Тәгаләнең Китабындагы кануннар, тәртипләр, имамыбыз ярдәме белән дәвам итик бу матур тормышыбызны. Туган йортыбыздай якын булсын, үзенә тартып торсын нурлы, имамлы мәчетебез.

Гөлсинә ГАЛИУЛЛИНА.
Әлки районы Карга авылы

Теләк булса, тау күчереп була

Әтием Гайнулла Камалов 1945 елда сугыштан кайткач, авыл мулласы булып киткән. Хәтта колхоз рәисе булып сайлангач та, бу эшен ташламады. Сугыштан соңгы авыр елларда авылдашларына рухи яктан да, физик яктан да булдыра алганча ярдәм итте. Салада нибары 4–5 кенә исән ир булгач, йортлар да салышты. Ә үзе кеше хезмәтен файдалана белмәде. Ачык кеше булганга, шөкер, өстеннән әләкләмәделәр. Аны бүген дә искә алалар.

Минемчә, авыл мулласы әнә шундый булырга тиеш ул. Сүземне раслап, тагын бер генә мисал китерәм дә, бүгенге хәлләрне бәян итәм. Әти безгә бүләккә төсле буяу-каләмнәр, карандашлар алып кайткан иде. Әнә шул карандашларны урталай бүлеп, авыл балаларына өләште. Әни: «Үзем гарәпчәгә өйрәтәм мин аны», – дип, мине мәктәпкә җибәрмәгән иде, әти беренче эш итеп җитәкләп уку йортына илтте. «Кызым, сугышта укый-яза белмәүчеләр хат яза алмыйча тилмерде, тырышып укы, гомер буе гыйлем тупла», – диде. Мин гомер буе укыган кешеләргә кызыктым, әмма үземә югары белем алырга насыйп булмады.

Инде хәзер Кара Чишмә мулласы Рөстәм Вәлиев турында бәян итәсем килә. Тырыш, эшкә батыр булуы белән авыл халкы күңеленә бигрәк тә хуш килә ул. Мин дә аны әтиләребез эшен дәвам иттерүче дип кабул итәм.

Безнең авыл зур, аның мәчете дә, клубы, кибете, мәктәбе дә бар. Авылга газы-суы кергән, юлына асфальт түшәлгән. Менә шушы авылга мәдрәсә кирәк иде. Безнең Рөстәм хәзрәтебез, авыл җирлеге башлыгы Рәдиф Халиков белән киңәшләшеп, төзелеш башларга булдылар. Икесе дә булдыклы, икесе дә – энергияле, булдырам дип торган егетләр! Нәтиҗәдә зур мәдрәсә калкып чыкты.

Рөстәм хәзрәт тә – муллалар нәселеннән. Шуңа мин «динне тыйган заманда» дигән сүзтезмәне бик өнәп бетермим. Теләк булса, тыеп булмый ул. Теләк булса, таулар күчереп була. Ә безнең авыл турында горурланып, беркайчан да дин кысылмады, дип әйтә алам.

Сүз азагында хыялымны да җиткерим. Мәдрәсә янында буш урын бар. Килер бер көн, шул урында эскәмияләр урнаштырып, балалар мәйданчыклары ясап, матур бакча оешып китәр әле. Ә бит шәһәрдә бу җәһәттән бик күп программалар бар, авыл өчен нишләп каралмаган икән алар?

Саимә МОРАТОВА.
Чирмешән районы Кара Чишмә авылы

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАЛА КҮҢЕЛЕНӘ АЧКЫЧ



Зурмы? – дисәң, зур түгелдер,
бу авыл бик кечкенә,
Халкының эчкән суы да бик кечкенә –
инеш кенә…

Габдулла Тукай бу юлларны әйтерсең лә безнең авылыбызга атап язган. Нәкъ Казан артында тавыкларын җырлатып, табигать кочагында җәйрәп ята Арча районы Урта Сәрдә авылы. Үзенең эшчән халкы, матур табигате белән билгеле. Авылыбыз үзәгендә, халкыбызны иманга өндәп, мәчет балкып тора. Мәчет төзелгәнгә – 11 ел. Мәчетебез имамы Нәкыйф хәзрәт авылыбыз халкына 11 ел хезмәт итә. Биредә һәр көн өйлә намазы, һәр атнада җомга намазы, ураза, Корбан гаетләре гөрләп уза, балаларга дин сабаклары укытыла.

Моннан берничә ел элек улыбыз бер ай дәвамында мәчет каршындагы җәйге лагерьга йөрде. Шушы җәйдә мәчет тормышы, имам һәм аның эшчәнлеге белән якыннан танышырга туры килде. Улыбызның беренче сыйныфны тәмамлаган елы иде бу. Беренче көнне аны мәчеткә үзем озата бардым. Безне елмаеп, ачык чырай белән: «Әссәләмәгаләйкүм! Хуш киләсез, рәхим итегез!» – дип, Нәкыйф хәзрәт һәм аның хатыны Дания абыстай каршы алдылар. Мәчеткә 8 – 11 яшьлек малайлар һәм кызлар җыелган. Авылыбыз балалары белән берлектә, безнең кебек, шәһәрдән әби-бабалары янына җәйге ялга кайткан балалар да байтак. Алар рус телендә аралашалар, шаярышалар. Араларында артык шуклары да күренә. Мин хәзрәткә һәм шәкертләргә уңышлар теләп, улымны калдырып кайтып киттем. Ә башымда төрле каршылыклы уйлар кайный: «Нишләп кенә бетәрләр икән болар монда?! Бигрәк күп бит болар! Араларында шәһәр «хулиган»нары да күренә. Яшьләре дә, буйлары да, белем дәрәҗәләре дә тигез түгел…

Беренче көнне үк көр күңел белән кайтып керде шәкертебез укудан. Шушы көнне без улыбыздан «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзенең мәгънәсенә төшендек һәм шул көннән башлап һәр эшебез һәм ниятебезне Аллага тапшырып, Аллаһы Тәгаләнең көч һәм кодрәтенә ышанып, ярдәменә өметләнеп башкарырга гадәтләндек. Һәр көн нәни шәкертебез өебезгә нинди дә булса яңалык, гыйлем алып кайтты һәм шул кагыйдәләрнең үтәлүен таләп итте. Ә без, әнисе һәм әбисе, бик рәхәтләнеп, имам өйрәткән ислам кагыйдәләрен яңадан өйрәнә башладык һәм үтәргә тырыштык. Өй эшләрен дә мулдан бирде мөгаллимнәр. Улыбыз, кич утырып, сүрәләр өйрәнде. Ә без аңа ярдәм итәргә тырыштык. Аның кычкырып-кычкырып өйрәнгән догалары, сүрәләре безнең дә хәтеребезгә иңә, аңыбызга үтә барды. Ә иң гаҗәбе шунда ки, мәктәптә укыганда өй эшләренә тотына алмыйча, вакыт үткәрергә тырышкан малайны алыштырдылар диярсең: үзе теләп эшкә тотына, ятлый, өйрәнә. Безгә дә тынгылык юк. Кәгазьдән карап барырга, төзәтергә куша.

Бер атна дигәндә бала берничә сүрәне яттан өйрәнде, байтак кына ислам кагыйдәләрен су кебек эчә иде. Үзем Казан мәктәпләренең берсендә педагог – психолог булып эшлим. Мине имамның балаларны ничек шул рәвешле эшкә юнәлтә алуы, эш алымнары, шәкертләр белән мөгамәләсе кызыксындырды. Дин сабаклары сәгать тугыздан унбергә кадәр дәвам итә. Ә дәресләрдән соң ял вакытлары башлана. Шул вакытны чамалап, «улымның хәлен белергә» дип мәчеткә барып килергә булдым. Мин килеп кергәндә дәресләре бетеп җитмәгән иде әле. Мәчет эчендә эшлекле атмосфера. Нинди дер миңа таныш булмаган доганы кабатлыйлар. Имам сабыр гына, әмма таләпчән кыяфәт белән, шәкертләрдән шул доганы укыта, кабатлата, кирәк урында ялгышларын төзәтә, кайбер җирләрдә мактап та ала. Менә чират безнең малайга да җитте. Каушап кына тотынды балакай, шулай да башкарып чыкты. Бу урында имам: «Яхшы, булдырдың! Тик шулай да бер хатаң булды. Балалар, кем сиздe Камилнең хатасын?» – дип сорады. Берничә кул күтәрелде. Хата төзәтелде. Хәзрәт Камилгә дә хатасын төзәтеп укырга кушты. Бу юлы инде Камил дә хатасыз укый алды. Улымның шатлыктан балкыган йөзен күрү миңа да бик рәхәт иде! Үзем дә шул дөньяга кереп киткәнемне сизми дә калдым, эчемнән хәзрәт артыннан мин дә кабатлыйм.

Иң мөһиме – аралашу татар телендә бара. Аңлавымча, бу – хәзрәт таләбе. Каударлану да, кабалану да, каушау да юк балаларда. «Чыктым аркылы күпер»ле җөмләләрне хәзрәт төзәтеп җибәрә. Балаларның йөзләрендә һәм күз карашларында бер-берләренә, бигрәк тә хәзрәткә ихтирам ярылып ята. «Хулиган» малайлар да басылганнар, салмак кына шул дулкында тибрәләләр.

Үземне кызыксындырган сорауларга һич җавап таба алмыйм, киресенчә, сорауларым арта гына бара. Мәктәптә дәресләрдә дә балаларны менә шулай сихри рәвештә белем дөньясына алып кереп китәрдәй алымнар эзлим… Дәрес тәмамланды. Балалар шау килеп, тышка мәчет мәйданчыгына чыгып киттеләр. Алар артыннан, мәчет киемен спорт киеменә алыштырып, хәзрәт тә чыкты. Монда балаларны алдан планлаштырылган уеннар, ярышлар көтә иде. Менә скакалка белән сикерү ярышы башланды. Бу шөгыль дә алдан әзерлекне таләп итә шул. Күбесе, шул исәптән безнең малай да, булдыра алмадылар. Имам аларга тагын бер өй эшен өстәде: тиз арада скакалка белән сикерергә өйрәнергә! Бер төркем малайлар футбол уйнарга юнәлделәр. Имам да малайлар арасында! Ул аларга футбол уенының кайбер нечкәлекләрен өйрәтте һәм малай-шалайлар белән футбол уйный башлады! Бу уеннан соң балалар кабат мәчеткә юнәлделәр. Монда аларны Дания абыстай белән кызлар табын әзерләп көтәләр иде. Мине дә өстәл янына дәштеләр. Менә без, бер гаилә булып, табын янында утырабыз. Бер генә бала да сабырсызланып ризыкка үрелмәде. Хәзрәтнең ризалыгын көтәләр. Хәзрәт, сабыр гына: «Әйдәгез, балалар, бүгенге көнебезгә йомгак ясыйк!» – диде. Балалар бүген «Аятелкөрси» догасын өйрәнә башлауларын, аның бер аятьтән генә торуын әйтеп үттеләр. Ә инде һәр көн нинди дә булса яхшылык, игелек кылырга, мәрхәмәтле булырга кирәклеген ашыга-ашыга, бергәләшеп әйттеләр. Шуннан соң гына балалар, күтәренке рух, көр тавыш белән бисмилла әйтеп, ризыкка үрелделәр.

Бу бәйрәмне башка бәйрәмнәр белән чагыштырып булмый. Ул балачак бәйрәмен дә, күңел кылларын тибрәткән рухият бәйрәмен дә хәтерләтә. Хәзрәттән: «Әйтегез әле, хәзрәт, балалар белән шундый эчкерсез матур мөгамәләгә, эшегездә уңышка ничек ирешәсез? Арада төрле балалар бар бит», – дип сорадым. Әйтерсең лә хәзрәт минем бу соравымны көтеп кенә торган: «Һәрбер баланың да күңел түрендә яхшылык ята. Шул яхшылыкка юлны табу һәм бала белән ихлас булу кирәк, сеңлем!» – дип, ихлас сүзенә басым ясап, җавап бирде. Менә сиңа мә! Минем күңелемдәге дилбегә буе озын сорауларыма – бер җавап. Хәзрәт киңәшләрен язгалап барырмын дип алган блокнот белән ручкамның кирәге дә чыкмады.

Улыбыз лагерь ахырына, башка балалар белән берлектә, намаз догаларын өйрәнеп бетерде! Хәзрәтебез оештырган спорт ярышларында призлы урыннар алды. Әкренләп өйдә саф татар телендә сөйләшүгә күчтек. Әтиебез «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керде һәм аны уңышлы тәмамлады. Мин үземнең эшемдә имамыбыз тәкъдим иткән ихласлык алымын уңышлы гына кулланып киләм. Әйтергә кирәк, балалар белән ихлас булу аларның күңелләренә иң кыска юл икәнне аңладым. Бу язмамда авылыбыз имамы, хаҗи Нәкыйф Әхәт улы Вәлиуллинның киңкырлы эшенең безнең гаиләбез белән бәйле булган бер юнәлешен чагылдырырга тырыштым. Ә авылыбызда гаиләләр күп. Һәрберсе дә имамыбызны чиксез хөрмәт итә.

Имамыбыз тормыш иптәше Дания ханым белән күпләргә үрнәк гаилә төзегән. Авылның иң чибәр кызын тәртипле, тырыш, булдыклы булуы, шуның өстенә оста гармунчы һәм җырчы булуы белән карата ул. Кулыннан килмәгән бер генә эше дә юк: агачтан йорт җиһазларын, тәрәзә рамнарын үзе эшли, маллар асрыйлар, бал кортлары тоталар; бакчаларында яшелчә, җиләк-җимеш уңа, аллы-гөлле чәчәкләр дә оста хуҗаларына дан җырлыйлар сыман. Бу эшчән гаилә бер малай һәм бер кыз үстерә.

Уллары Ренат Вәлиуллин – күпсанлы фәнни эшләр авторы, филология фәннәре кандидаты. Бүген Санкт-Петербург шәһәрендә Татарстанның вәкаләтле вәкиле хезмәтен башкара. Кызлары Резедә Вәлиуллина-Хәбибрахманова укытучыларның белемнәрен күтәрү институтында укытучы-методист булып эшли.

Менә шундый безнең авылыбыз имамы – Нәкыйф Вәлиуллин! Мин язмамны тәгалләп утырганда, авылыбызны яңгыратып, аның азан әйткән тавышы ишетелде: «Хәййә галәс саләһ! Хәййә галәл фәләх!» Гүя шул рәвешле халкыбызга иман һәм бәхет орлыкларын тарата. Орлыкларга шытып чыгар өчен барлык шартлар да тудырылган. «Иманлы, мәрхәмәтле, игелекле, бәхетле булсын халкым!» – дип хыяллана хәзрәтебез.

Илмира САЛИХҖАНОВА.
Казан

ИДЕЛДӘ УЛЫН ЮГАЛТКАН АНА:

«Йөрәгем сизгән иде»

Искә алу

Шушы көннәрдә Иделдә «Булгария» теплоходы бату фаҗигасенә 11 ел булды. Якыннарын югалткан кешеләрнең күңелендә әле дә тирән яра. Вакыт – дәва, дисәләр дә, бу сүзләр берәүне дә юатмый. Күңелләре белән кемдер баласын, кемдер әти-әнисен, туганын көтә. Әйтерсең ялга гына киткәннәр, кайтып керерләр кебек. Нишлисең, истәлекләр белән юанып яшәргә кала.

Фаҗигадә әти-әнисен югалткан Алмаз (сулда) ятимлек ачысын сиздермәгән өчен әби-бабасына, туганнарына рәхмәтле.

Июнь ахыры – июль башы җитәрәк, бөтен тәнем калтырый башлый, ди Казанда яшәүче Илназ Садриев.

– Апам белән җизнәмнең теплоходта ял итеп кайтасылары килде. Бер генә көнгә дип киттеләр, юкса… 14 ел бергә матур итеп яшәде алар. Гел эштә иделәр инде. Бергә ял итәселәре килде. Шушы ял соңгысы булыр дип кем белгән… – ди Илназ.

Апасы Гөлназның ике баласы ятим кала. Ул чакта олы кызы Энҗегә – 12 яшь, Мәликәгә 2 генә тулып киткән була. Олысы инде әнисез калганын аңлап еласа, кечесе дә үксеп-үксеп, әни таптыра. Әниләре Рәдифә апага аеруча кыен икән. Фаҗигадән соң алар ире белән ике кызны үзенә алалар. Ничек тә алга таба яшәргә тырышалар. Йөрәкләре тулы яра булса да, оныкларына күрсәтмиләр. Бу көннәрдә шул яралары кузгалган, Рәдифә апаның авыр чагы. Шуңа да без Илназ белән аралаштык.

– Бу хәсрәт безне гомер буена озатып барачак инде. Әле беркөнне дус егет бәйрәмгә чакырган иде. Шунда бер абый белән сөйләшеп киттек. Ул да Иделдә кызын, киявен, оныгын югалткан икән. Фаҗига булган вакыт якыная башлауга, хәлем читенләшә, бик кыен, ди ул да. Без дә шул хәлəттә. Апамның балаларын күреп, үзебезне кулга алабыз. Олы кызы Энҗе тиздән диплом алачак. Югары уку йортын тәмамлады. Казанга килгәч, ул бездә булды инде. Әле дә бергә яшибез. Ике ел элек әтиебез арабыздан китеп барды. Ул ачы хәсрәтне авыр кичерде. Елап та булмый бит, ди иде. Хәзер Мәликә сеңлем әнием белән яши. Җиденчегә бара инде.

Яшел Үзәндә яшәүче Дилбәр Дәминова да фаҗигадә туганнарын югалта. Апасының улы белән килене ялга дип китеп, кире кайтмый. Киленнәре улы Алмазга иптәшкә бәби дә көткән була әле.

– Шушы Алмаз улыбыз булмаса, бу кайгыны ничек күтәрер идек. Аллага шөкер, Алмаз зур егет булып үсеп килә. Озын буйлы, чибәр. Бию түгәрәгенә йөри. Әтисе белән әнисе күрсә, сөенерләр иде, – ди ул. – Фаҗига безне берләштерде. Авыр чакта бар туганнар янәшә булдык. Сабый ятимлекне сизмәсен өчен тырыштык. Сеңлем Ильмира белән киявебез Альберт гаиләсе дә Алмазны үз итеп, яратып яши. Улыбыз инде еламый, барысын да аңлап, әти-әнисе, әби-бабасы, якыннары горурлансын дип яши.

Арча районының Зур Бирәзә авылында яшәүче Сания Мифтахова фаҗигадә улы белән киленен югалта. Ана күңеле сизенә ул чакта. Улы Илнур да алдагы көнне начар төш күрә. «Әни, болганчык су күрдем», – ди. Әнә шуңа да Сания апаның аны бер дә җибәрәсе килмәгән.

– Киленем эшкә чыгам дигәч, кечкенә оныгымны карап тордым. Ул чакта балага 1 яшь тә 3 ай гына иде әле. Йә кодагый, йә мин ярдәм иттек. Аннары алар улым белән теплоходта йөреп кайтабыз, диделәр. Бер дә Илнурның китүен теләмәдем. Йөрәгем сизенде. Улым да минем борчылганны аңлады. «Бер тапкыр барам да башка бармыйм», – диде. Шулай булды да. Фаҗига җиткән көнне генә түгел, ел әйләнәсе читен миңа. Бик тә балаларны сагынам. Ачы хәсрәтләр белән яшәүдән дә авыр хәл юк икән, – ди ул.

Кем белән сөйләшсәң дә, юатыр сүзләр табу кыен. Сүзләр артык та монда. Бер генә теләк: күргәннәргә сабырлык бирсен Ходай. Һәркемнең – үз язмышы, хәсрәт дигәнең берләштерә… Якыннарын югалтканнар көчле булырга өйрәнгән. Күбесе оныклар хакына күз яшьләрен эчкә йота.

Сүз уңаеннан, Быел «Булгария» теплоходы баткан көнне, 10 июльдә Иделдә аздан гына янә фаҗига булмый кала. Казанның Аракчино бистәсе янәшәсендә теплоход суга бата. Бәхеткә, пассажирларны тиз коткаралар. 34 кеше исән-сау ярга чыгарыла. Әлегә фаҗиганең нечкәлекләрен тикшерәләр.

Исегезгә төшерәбез: «Булгария» фаҗигасе 2011 елның 10 июлендә 13 сәгать 30 минут тирәсендә Куйбышев сусаклагычының Сөйки авылы (Кама Тамагы районы) янында килеп чыга. Казан – Болгар – Казан маршруты буенча сәяхәткә чыккан теплоходта булган 201 кешенең 79ы исән кала. 122 кеше үлә, аларның 28е – балалар. 2012 елның 10 июлендә һәлак булганнар истәлегенә яр буенда хәтер комплексы ачыла. Анда мәчет һәм часовня урнашкан.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Миллият

ИПТӘШ, ТОВАРИЩ ҺӘМ ЮЛДАШ

Әлки районы Сихтермә-Хузангай авылында Россия күләмендә чуаш мәдәнияте бәйрәме Уяв гөрләп узды. Әлки җиренең беркайчан да моның кадәр кунакны күргәне юк иде әле. Бәйрәм, гүя кайгыртучан ана, барчасын үз канаты астына җыеп, һәркемгә күңел җылысын, өмет-ышанычлар бүләк итте. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм башка дәрәҗәле кунаклар катнашты. Алар чуашларның милли киеменнән иде.

tatarstan.ru

Илебезнең төрле почмакларыннан 108 фольклор коллективы, республикада, күрше төбәкләрдә яшәүче чуашлар – барлыгы 10 меңнән артыграк кеше гаять зур мәйданга җыелды. Ак яки алсу җирлеккә кызыл төстәге милли бизәкләр төшкән киемнәрнең җетелеге, күзләрне камаштырып, мәйданны әкият аланына әйләндерде.

Уяу бул, димәктән

«Уяв» сүзе «үтәргә» дигәнне аңлата. Татарларның «уяу булырга» дигән сүзтезмәсенә якынрак мәгънәдә. Уяу булып, гомер-гомергә килгән гореф-гадәтләрне үтәргә, сакларга кирәк, ягъни.

Бәйрәмнең рәсми ачылышына кадәр Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, КПРФ лидеры Геннадий Зюганов, Чуашстан Республикасы башлыгы Олег Николаев, Ульяновск өлкәсе губернаторы Алексей Русских, дәрәҗәле башка кунаклар чуаш халкының тарихы турында сөйләүче милли утарлар белән танышты.

Әйтергә кирәк, кунакларның барысы да чуашларның милли киеменнән иде. Аларны милли аш-су – итле ботка һәм сыра белән сыйладылар. Шуннан соң иҗат коллективлары бәйрәм кунакларын үзләренең җыр-биюләре нигезендә мул уңыш теләү (Учук), балага исем кушу (Ачана ят хуни), армиягә озату, туй (Чавашла туйе), кич утыру (Улах) кебек гореф-гадәтләр белән таныштырды. «Йорт төзү өмәсе»ндә исә Татарстан Президенты үзе үк агач кайрысын юнып күрсәтте.

Рөстәм Миңнеханов сәламләү сүзендә мәйданга җыелган барча халыкны Уяв милли бәйрәме белән котлады.

– Бүген бездә бик күркәм бәйрәм. Кадерле кунакларны кабул итү – безнең өчен зур дәрәҗә. Кунакчыл Әлки җирендә барыгызны да бәйрәм белән котлыйм! Әлеге бәйрәм традицияләре безгә тамырлары бик еракларга барып тоташкан үзенчәлекле чуаш мәдәнияте дөньясын ача. Уяв, татарларның Сабан туе, удмуртларның Гырон-Быдтоны, мариларның Семыгы, мордваларның Валда Шинясе кебек, республиканың мәдәни брендларыннан берсенә әйләнде, – дип билгеләп үтте ул. – Чуашлар – үзенең телен, традицияләре һәм гореф-гадәтләрен кадерләп саклаучы эш сөючән халык. Алар Татарстанның бердәм гаиләсендә лаеклы урын алып тора, республиканы үстерүгә зур өлеш кертә, күпмилләтле мәдәниятебезне баета.

Президент басым ясап әйткәнчә, бүгенге катлаулы вазгыятьтә күп гасырлар дәвамында тупланган рухи кыйммәтләрне сакларга һәм арттырырга кирәк. Туган телгә һәм гаиләгә ихтирамлы мөнәсәбәт, төрле милләтләр, төрле диннәр вәкилләре арасында тынычлык-татулыкны алга таба да саклау шарт.

– Уявның чуаш халык шагыйре Петр Хузангайның туып үскән авылында узуы аерым бер әһәмияткә ия. Быел аның тууына 115 ел тула. Шагыйрьнең әсәрләре үз халкы һәм Ватанына эчкерсез мәхәббәт хисләре белән сугарылган, – диде Рөстәм Миңнеханов, Хузангайның улы Атнерны, хатыны һәм оныгын сәламләп.

Дуслык бәйрәме

КПРФ лидеры Геннадий Зюганов исә үзенең чыгышында халыклар арасындагы дуслыкның фашистлар Германиясен җиңүдәге ролен билгеләп үтте.

– Безнең бөек илебез фашизмны җиңде, галәмгә юл ачты, ракеталар, атом-төш өлкәсендә уңышларга иреште. Моның өчен безгә тарихның гадел хөкеме иң бөек һәйкәл куячак. Бу һәйкәлне халыклар булдырды. Бер генә тел дә, дин һәм мәдәният тә читтә калмыйча, 190 халык вәкиле илебез әләме тирәсенә тупланды. Бу гүзәл почмакта без үзебезне бердәм гаилә, бертуганнар кебек хис итәбез, – диде ул.

Партия җитәкчесе әлеге данлыклы җирдә бәйрәм итү, лаеклы төстә яшәү һәм эшләү, Иван Казанков кебек халык предприятиеләрен булдыру үрнәген күрсәткән өчен республика Президентына рәхмәт сүзләре җиткерде. «Казанковның туып-үскән җирендә бөтен көчен куеп, үз халкына хезмәт итә башлавына, тырыш хезмәт нигезендә аны берләштерүенә киләсе елда ярты гасыр була инде», – диде ул.

Бәйрәм төнгә кадәр дәвам итте. Зур мәйдандагы берничә сәхнәдә һәркем үзенең талантын күрсәтеп калырга ашыкты. Балалар өчен мавыктыргыч уеннар һәм аттракционнар оештырылды, яшьләр командалары пляж волейболы буенча көч сынашты, бокс сөючеләр Россиянең төрле почмакларыннан җыелган иң көчле яшь спортчылар ярышларын карады, ә инде төбе күренеп торган чип-чиста сулы буада яшь парлар көймәләр һәм катамараннарга утырып йөзде.

Әлбәттә инде, ат чабышлары да булды. Сүз уңаеннан, Евгений Чугунов җитәкчелегендәге «Хузангай» җәмгыяте быел Орел юртагы токымлы чабышкылар юнәткән. Шуңа күрә чабышта Әлки бахбайларына тиңнәр табылмады.

Якташыбыз Петр Хузангайның: «Күрше татар, рус һәм чуаш авылларында яшәүчеләр бер-берсенә иптәш, товарищ һәм юлдаш дип эндәшә», – дигәнрәк сүзләре бу көнне кат-кат кабатланды. Теләсә кайсы бәйрәмнең төп әһәмияте – рухи бердәмлек тудыру, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү, кешеләрне бергә туплау. Кыскасы, Уяв безгә бер елга җитәрлек көч-куәт өстәп, туган төбәгебез, туган телебез һәм мәдәниятебез өчен горурлык хисләрен тагын да көчәйтте.

Лия МӘРДЕГАЛЛӘМОВА

Фикер

Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ,
Татарстан Премьер-министры урынбасары:
– Безнең республика күпмилләтле. Чуашлар халык саны буенча өченче урында тора. Традиция буенча Уяв Нурлат районында уздырыла иде. Берничә ел Аксубайда бик матур итеп оештырылды. Һәр районның үзенә генә хас үзенчәлекләре, үз мөмкинлекләре, данлыклы шәхесләре бар. Әлки төбәге Сихтермә-Хузангай авылында туган Иван Казанков белән данлыклы. Әлеге искитмәле бәйрәм нәкъ менә шуның башлангычында үткәрелә. Моның өчен аңа зур рәхмәт. Бәйрәм була да бетә. Ә менә аның өчен төзелгән инфраструктура бетми. Барысы да халыкка кала.

Любовь МИКУШЕВА,
Базарлы Матак район үзәк хастаханәсе табибы:
– Күңелем бәйрәм шатлыгы, үзебезнең чуаш халкы белән горурлану хисләренә тулы. Бирегә бүген Россиянең төрле почмакларында яшәүче чуашлар җыелды. Күп кенә якташларымны, сыйныфташлар, авылдашларны очраттым, атаклы кешеләрне күрдем, хәтта Чуашстан телевидениесе җитәкчесе белән фотога да төштем. Иван Казанковка, аның башлангычын хуплаган республика җитәкчелегенә һәм, әлбәттә инде, уй-ниятләрнең тормышка ашуы өчен мөмкин булганның барын да эшләгән район хакимияте башлыгына рәхмәт!

КҮЛ ТИРӘСЕ – МӘХӘББӘТ БОҖРАСЫ

Автор фотосы

Төрле халыкларны – бер әйлән-бәйләнгә! Яшел Үзәндә беренче тапкыр славян мәдәнияте бәйрәме Иван Купала узды. Республика күләмендәге тәүге шундый бәйрәм Татарстанда яшәүче рус, белорус, татар, мариларны бер урынга җыйды.

Әйлән-бәйлән

Шәһәрдә яшәүчеләрнең яраткан күлендә, Үбешүләр күпере тирәсендә, сал йөзә. Акка кызыл бизәкләр төшкән чигүле күлмәкле егет белән кыз, кояш һәм су алиһәләренә баш иеп, суга ромашкадан үргән такыялар сала. Ә күл яры буйлап, 1932 биюче кулга-кул тотынышып, җыр көйләп, әкрен генә атлый. 90 ел элек – нәкъ менә 1932 елда Паратск бистәсе, шәһәр статусын алып, Яшел Үзән шәһәренә әйләнә.

… Җыр тәмам. Барысы да «Авангард» мәйданына юнәлде. Биредә – бәйрәмнең төп мәйданчыклары. Адашып калам димә: мәйданчыкка илтүче сукмак тирәсе аллы-гөлле чуклар һәм агачтан уеп ясалган сыннар белән бизәлгән.

Балалар музыка мәктәбе янындагы «Ракушка» сәхнәсендә Татарстанның 30 районы һәм шәһәре – Алексеевск, Лаеш, Минзәлә, Алабуга, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсеннән һ.б. килгән кунаклар, берсеннән берсе уздырып, халык җырларын башкарды. Татарстан Халыклар ассамблеясыннан «Мрія» ансамбле солисты Олеся Камзина, Яшел Үзәннең Горький исемендәге Мәдәният үзәгеннән Йолдыз Шәмгунова җитәкчелегендәге «Русь» халык вокаль ансамбле чыгышлары тамашачыларны тәмам әсир итте.

Гаиләләрне данлау

Шәһәр мэры Михаил Афанасьев дәрәҗәле кунаклар белән күргәзмәне карады, бура (городки) уйнады, матур язу буенча мастер-класста булды. Татарстан Премьер-министры урынбасары Роман Шәйхетдинов, хакимият башлыгын һәм шәһәр халкын яңа бәйрәм уңаеннан котлап, аның җиребездә озак елларга сакланып калуын теләде.

Ул арада иҗат коллективлары тамашачыларның күңелен күрде. Бөгелмәдән «Зарев» (августның борынгы атамасы шулай булган) казак ансамбле дәртле җырларын яңгыратты. Этнофестиваль үз тирәсенә кул эше осталарын җыйды. Агачтан уеп ясаучылар, тимерче, балчык осталары, челтәр бәйләүчеләр, тегүче, флористлар… Кулдан эшләнгән әйберләргә мөкиббән китүчеләр агач арба рәвешендәге киштәләр янынннан бер секундка да өзелеп тормады.

Менә сәхнәгә гаилә тормышы ветераннары күтәрелде. Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина һәм Яшел Үзән районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Денис Лулаков Гатауллиннар, Ананьевлар, Зәйнуллиннар гаиләсенә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медален тапшырды. Шәхси тормышларында түгәрәк датаны билгеләп үтүче 11 гаилә парына бүләкләр тапшырылды, изге теләкләр теләнде.

Халык күңеле – җырда

Халык җырларын башкаручы, халыкара фестивальләр һәм бәйгеләр лауреаты, «Халык артисты-3» телепроекты финалына чыккан Марина Девятова, Мәскәүдән «Крапива» этно-төркеме чын мәгънәсендә бәйрәм күркенә әйләнде. Аларның моңлы да, дәртле дә җырларына мәйдандагы бөтен халык кушылды! Сүз уңаеннан, Яшел Үзәндә Иван Купала бәйрәменә 20 меңнән артыграк кешенең җыелуын искәртеп үтәргә кирәк.

Бәйрәм дәвамында агачтан уеп ясаучылар мәш килде. Алар Иван Купаланың төп геройларыннан берсе – урманның явыз көчләрен ясады. Ниһаять, агач аждаһаларны яндырырга вакыт җитте. Алар шәм кебек очкынланып кабынса да, озак – ярты сәгать чамасы янды. Шуннан соң бәйрәмнең иң кызык өлеше – «Джива» ут театрының очкынлы-ялкынлы «Жар-птица» тамашасы башланды. Бик зур абага чәчәге сыман, чыршыда бенгаль утлары кабынды.

Юлия ОЗЕРОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 298

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+